Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Ялтаны авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре № 7

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлегенең Татар Ялтаны авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 18 ноябрендә 14.00 сәгатькә авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлегенең Татар Ялтаны авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Ялтаны авылы, Кооперативная ур., 9 нчы йорт.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлегенең Татар Ялтаны авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- Татар Ялтаны авылы урамнарында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китерү, грунт салу, гредирование, вак таш салу, грейдирование, кар чистарту);

- Татар Ялтаны авылында зират территориясен төзекләндерү (материаллар сатып алу, коймалар урнаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Татар Ялтаны авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Татар Ялтаны
авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарифуллин